# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Красный Бор торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**15.11.2021** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының районының «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Красный Бор торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2021 елның 15 ноябрендә 08:00, 11:00, 13:00, 15:00 сәг уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Красный Бор пункты территориясендә, I, 2 төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Красный Бор торак пунктын төзекләндерү
2. Юлларга хезмәт күрсәтү - урамнарны кардан чистарту (хезмәт килешүе буенча түләү).
3. Вак таш сатып алу һәм юлларны каплау, грейдерлау (хезмәт шартнамәсе буенча түләү)
4. Красный Бор торак пунктында санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү
5. Балалар мәйданчыгы төзү, балалар уен комплексларын сатып алу һәм урнаштыру.
6. Мәдәният йортында Красный Бор авылы тарихы музеен төзү өчен бинаны агымдагы ремонтлау.
7. Адресацияләрне яңарту (урамнарның исеме, йортларның нумерациясе)

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 1005 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 514 кеше, бу 51,1 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 514 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Красный Бор торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Красный Бор авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Красный Бор торак пункты территориясендә, I,2 төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1. Красный Бор торак пунктын төзекләндерү
2. Юлларга хезмәт күрсәтү - урамнарны кардан чистарту (хезмәт килешүе буенча түләү).
3. Вак таш сатып алу һәм юлларны каплау, грейдерлау (хезмәт шартнамәсе буенча түләү)
4. Красный Бор торак пунктында санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү
5. Балалар мәйданчыгы төзү, балалар уен комплексларын сатып алу һәм урнаштыру.
6. Мәдәният йортында Красный Бор авылы тарихы музеен төзү өчен бинаны агымдагы ремонтлау.
7. Адресацияләрне яңарту (урамнарның исеме, йортларның нумерациясе)

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы

А.Н.ЛАЗАРЕВ